БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«01» 06 2026 г. № 63

**Балтач муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән объектларны финанслау күләмнәрен бүлеп бирү һәм раслау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгы Р. Р.Нотфуллинның күрсәтелгән объектларда капиталь ремонт үткәрү кирәклеге турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, смета документларын әзерләү, капиталь ремонт буенча чараларны гамәлгә ашыру максатларында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1. Объектларны капиталь ремонтлау чыгымнарын финанслауга Балтач муниципаль районы бюджеты акчаларын бүлеп бирүне расларга:

- «Сосна балалар бакчасы» МБМББУ га капиталь төзекләндерү, адресы: Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы, Түбән Сосна ав., Герой Сәрвәр ур., 4 й., » – 51 199, 58 мең сум;

- «О.Н. Исаев исемендәге Урта Көшкәт урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ бинасына капиталь төзекләндерү үткәрү, мебель, җиһазлар һәм инвентарь сатып алу »- 196 831, 22 мең сум;

- «Чепья урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ бинасына капиталь төзекләндерү үткәрү, мебель, җиһазлар һәм инвентарь сатып алу» - 205 256, 70 мең сум.

2. Әлеге проектны гамәлгә ашыру кысаларында төзүче (заказчы) функцияләрен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты башкара дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чараларны Балтач муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары кысаларында финансларга.

4. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты белән берлектә чираттагы финанс елына бюджет проектын төзегәндә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән объектлар буенча төзелеш-монтаж эшләренә һәм аларга бәйле чыгымнарга түләү өчен дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе нигезендә билгеләнгән күләмдә максатчан ассигнованиеләр бүлеп бирүне күздә тотарга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетны формалаштыру, икътисад һәм социаль-икътисадый үсешне фаразлау буенча даими комиссиягә йөкләргә (рәисе Р.Х. Һадиев).

7. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин